ЯРДӘМ БУЛЫРМЫ?
Татарстанда җир чәчелми калыр дигән курку юк
> 2



ЯЛГАН БӘҺАСЕ
Фейк өчен штрафлар зур булачак
> 2

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ
«Ул чынлап та куш йөрәкле бугай...»
> 4

ЯЗ БӘЙРӘМЕ
Кемгә – чәчәк, кемнәргәдер назлы сүз җитә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 32 (28805) | Шимбә | 5 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Соклану

АЙГӨЛНЕҢ ГӨЛЛӘРЕ

Бар нәрсә гүзәл заттан тора! Хатын-кызның кәефе яхшы булса, өйдәге мәчегә кадәр бәхетле. Казан шәһәрендә яшәүче Айгөл Темирбулатова, уенынчынын бергә кушып, әнә шулай ди. Гөлләргә үлеп гашыйк героем тормыш иптәше Дамир белән берсеннән-берсе матур, гөлдәй өч кыз үстерә. Гүзәл затларның күркәм бәйрәме алдыннан Айгөл белән хатын-кыз бәхете, кыз бала тәрбияләү серләре турында сөйләштек.

Айгөл Темирбулатова тумышы белән Кама Тамагы районының Балтач авылыннан. Күпләргә «Инстаграм» челтәре аша таныш ул. Айгөлнең бередә саф татар телендә алып барган сәхифәсен даими күзәтеп барам. Бу юлларны укуга: «Хәзер бөтен кеше блогер инде ул», – диючеләр дә табылыр. Ләкин Айгөлнең блогы нәкъ менә хатын-кыз, әни булуның ни дәрәҗәдә зур бәхет икәнен раслап торуы белән игътибарны җәлеп итә. Нотык та сөйләми, акыл да сатмый – аның көндәлек тормышын күзәткәннән соң үзеннән-үзе шундый нәтиҗәгә киләсең. Айгөлнең бала тәрбияләү мәсьәләсенә дә мөнәсәбәте үзгә. Сәхифәсендә дә үзе белән «әни-кайфушница» дип таныштырган ул.

– «Әни-кайфушница» дигәндә ана булудан тәм табып, баланың көйсезләнүенә, кыек гамәлләренә игътибар итмичә, каты бәрелмичә, алар белән уздырган һәр мизгелдән тәм табып яшәүне күздә тотам. Үзем бүген нәкъ менә шушы бәхетле халәттә яшим. Кызлы әни – бәхетле әни. Кыз бала – әйтеп бетергесез бер галәм, – ди Айгөл. – Кемгәдер бәхетле булу өчен балаларны каядыр илтеп, калдырып торырга кирәк. Мин исә балаларым белән бергә ял итүдән тәм табам. Өч баламны ияртеп каядыр барып кайту да минем өчен берни түгел.

Әңгәмәдәшемне якыннан белгән кешеләр алдарга ирек бирмәс. Айгөл күпләрне үзенең сабырлыгы белән дә таң калдыра. Баланың саксыз кагылуы аркасында өр-яңа диванга биш-алты гөл үсеп утырган киштә килеп төшеп, диван өстендә туфрагы-ние белән гөлләр аунап ятуын күз алдына китерегез әле. Бу очракта, балага ярсымыйча, кычкырмыйча, үзеңне кулда тотып калуы, ай-һай, авыр. Айгөл исә туйганчы бер кычкырып көлде дә эшне уенга борды – шуның белән вәссәлам. Аның көндәлек тормышында моныңише мисаллар бихисап. Язылучыларыннан килгән: «Айгөл, син нинди тынычландыручы дарулар эчәсең ул?», «Ничек шулкадәр тыныч булып кала аласың?» ише сорауларга да ияләшеп бетте инде ул. Әмма беренче карашка йомшак кебек тоелса да, Айгөл үзен усал әни дип саный.

– Мин рөхсәт иткән һәм мин кабул итми торган әйберләр бар. Балаларның шуклыгы – минем өчен аларның үсешен күрсәтә торган нормаль күренеш. Ашау, ризык мәсьәләсендә исә мин бик таләпчән. Балага сораган бер нәрсәсен сатып алу яклы да түгелмен. Болай эшлибез, болай – юк, дип алдан ук сөйләшеп куям. Бездә əти-әнигә каршы дәшү дигән әйбер юк. Үземә дә алар белән алай сөйләшергә рөхсәт бирмим. Тәрбия мәсьәләсендә бала мәнфәгатьләре дә, ата-ана мәнфәгатьләре дә кайгыртылырга тиеш. Мин баланы патша урынына куюга каршы, – ди Айгөл. – Миңа калса, бала тәрбияләгәндә төп өч әйбергә игътибар итәргә кирәк. Шуның беренчесе – ярату. Хәзер күп кенә ата-ана, баланы иркәлим дип, аны артык еш кочакларга, үбәргә курка. Әмма ярату бит ул кибеттәге бөтен уенчыкны сатып алу түгел. Ярату, наз белән баланы берничек бозып булмый. Балага сайлау мөмкинлеге, үзе теләгәнчә яшәргә ирек бирү дә мөһим. Аны кечкенә генә уңышлары өчен дә мактап, матур сүзләр белән үсендереп торырга да кирәк.

Айгөлнең яратып әйтә торган сүзе бар. Өйдәге һава торышы хатын-кызның кәефенә бәйле, ди ул. «Хатын-кызның кәефе яхшы булса, өйдәге һәркем бәхетле. Хәтта мәченең дә кәефе күтәренке була. Андый чакта баланың көйсезләнүенә дә җиңелчә карыйсың. Иреңнең төртмәле сүзләренә дә исең китми», – ди Айгөл.

Ир дигәннән, хатын-кызның бәхете ирдән диюемә, ир-атның да бәхете хатын-кыздан дип өстәп куйды әңгәмәдәшем. Яшерен-батырын түгел, бүген хатыннары кубызына биюче ирләр дә, җәбер-золым, психологик басымга дучар булып яшәүче хатын-кызлар да байтак. Айгөл Темирбулатова, мәктәпләрдә, элеккеге кебек, әхлак дәресләре укытылса, мондый бәхетсез җаннар азрак булыр иде, дигән фикердә. «Аллаһка шөкер, миңа яхшы ир эләкте, дип сөенәм. Ә бит яшь чакта күз томаланган була, насыйп ярыңны сайлаганда хаталана да аласың. Өйләнгәч, исерек айныр, сугыш чукмары сугышудан туктар дип өметләнү – зур хата. Булачак ирен сайлаганда хатын-кыз хис белән түгел, акыл белән эш итәргә тиеш. Бу хакта гаиләдә дә бик аз сөйләнә. Шуңа күрә монда әхлак дәресләре бик кирәк», – ди ул.

Хәзерге тынгысыз, тотрыксыз заманда иркә гүзәл зат булып кына яшәве бик кыен. Әмма мөмкин. Айгөл моның төп серен үз-үзеңне яратуда, кадерләүдә, үз-үзеңә вакыт таба белүдә күрә. Үзе үк зур бәхет бу. «Гаиләле, балалы булуың, күңелең тыныч булу, эшләгән эшеңнән тәм табуың да – хатын-кыз бәхетенең алыштыргысыз өлеше. Синең кияүдә була торып та ирекле булуың бәхет. Ирекле дигәндә, иреңнең көнләшеп, һәр нәрсәдән гаеп табып үзәгеңә үтмәвен, сиңа тулысынча ышануын күздә тотам. Соңгы сүз ир кешедә булырга тиеш. Әмма синең сүзеңә дә колак салулары мөһим», – ди Айгөл. Тагын бер 20–30 елдан да үзен әнә шундый үз тормышыннан канәгать булган бәхетле хатын-кыз, энергиясе ташып торган, актив дәү әни итеп күз алдына китерә ул. Айгөлнең кияүләрен дә бәхет басачак. «Алар өчен дә үзләре белән бер дулкында, дустанә мөнәсәбәттә булган супер теща булачакмын», – дип көлдерде әңгәмәдәшем.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ХАТЫН-КЫЗ – ҮЗЕ БЕР ҖИҺАН

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның 8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле хатын-кызлар!

Сезне 8 март – Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан чын күңелдән котлыйм.

Кояш ягымлы карап, көмеш тамчылар биешә башлауга озак та узмый язның тәүге бәйрәме җитә, ул кышкы салкыннардан арыган йөрәкләргә җылы өсти, ир-атларны гүзәл ханым-туташлар хакына күркәм гамәлләргә рухландыра. Бу тантанага әзерләнгән чакта безнең җаннарда кадерле кешеләребезгә – дәү әни, әни, хатын, сеңелләребез, кызларыбызга карата иң садә, иң саф хисләребез тагын да көчәя.

Хатын-кыз – үзе бер җиһан һәм анда назга, ратуга һәм гүзәллеккә, ана мәхәббәтенә, гаиләне саклау, газизләренең хәленә керә белү, киң күңеллелек кебек асыл хасиятләргә – һәммәсенә мәйдан киң. Табигатьтән бирелгән күркәм сыйфатларыгызны сез юмартларча башкалар белән дә бүлешәсез. Шәфкатьле, мәрхәмәтле ана сабыена гомер бирә, бишектән үк аны туган телгә, ата-бабаларның гореф-гадәтләренә, йолаларына мәхәббәт һәм хөрмәт рухында тәрбияли.

Булдыклы, сәләтле хатын-кызларыбыз бихисап күп безнең, нинди генә эшкә тотынсалар да, алар уңышка ирешә. Бөек илебез үзенең спортчы кызлары күптән түгел Пекинда узган XXIV Кышкы Олимпия уеннарында яулаган җиңүләр белән хаклы төстә горурлана. Казанда туган яшь фигуристкабыз Камилә Вәлиеваның чыгышларын ихлас күңелдән дулкынланып күзәттек, аңа изге теләктә булдык. Киләчәктә Камиләнең спортта зур казанышларга ирешәчәгенә минем берниндә дә шигем юк.

Медицина тармагында, социаль өлкәдә эшләүче, тәрбияче һәм укытучы хатын-кызларга олы ихтирамыбызны һәм рәхмәт сүзләребезне җиткерергә телим. Алар ирләр белән беррәттән фидакарьләрчә мәкерле чиргә каршы көрәшә, кешеләр сәламәтлеген кайгырта, катлаулы шартларда халыкка ярдәм күрсәтә, татарстанлыларның яшь буынына белем бирүдә армый-талмый хезмәт куя.

Тарихта иң дәһшәтле сугышның бар авырлыгын каһарманнарча кичергән, илне торгызуда һәм яңа тормыш төзүдә катнашкан ветеран хатын-кызларыбызны аеруча олуглап бәйрәм белән тәбриклим. Сез безнең өчен һәрчак түземлек, тугрылык һәм ватанпәрвәрлек үрнәге булып торасыз.

Йөрәкләргә яшәү дәрте өсти торган ямьле бәйрәм сезнең һәрберегезгә, кадерле хатын-кызлар, бик күп сөенечләр, якты уйлар, рухи күтәренкелек, киләчәккә матур өметләр бүләк итсен!

Сезгә тынычлык, бәхет, сәламәтлек, мәхәббәт, игелек һәм иминлек телим!

Көн кадагында

Вакыт отарга тырышу файдага түгел

Россия – Украина делегацияләренең икенче очрашуы чәршәмбе көнне планлаштырылган булса да, украин ягының таләпләрне даими үзгәртеп торуы сәбәпле, пәнҗешәмбе кичендә генә оешты. СССРның таркалу урыны булган мәшһүр Беловежеская пущага Киев сәясәтчеләре башта килергә теләмәделәр. Берникадәр сузып булса да, сөйләшүләр башланды ләкин.

Пәнҗешәмбе көн тарихка бик тыгыз мәгълүмат ташкыны белән язылды. Башта Путин – Макрон телефон элемтәсе булды. Сөйләшү барышында Путин француз коллегасының утны туктату турындагы тәкъдимен кире какты: «...сөйләшүләрне сузып вакыт отарга тырышу Россиянең сөйләшүләр позициясендә Киевка карата өстәмә таләпләре пәйда булуына гына китерәчәк», – диде. Элемтәдән соң Макрон: «...иң начары алда икән әле», – дип әйткән дигән хәбәрләр күренгәләде.

Владимир Путин шулай ук Куркынычсызлык Советы әгъзалары белән видеоконференция режимында оператив киңәшмә үткәрде, киңәшмә алдыннан ватанпәрвәрлек белән сугарылган нотык тотты, дагыстанлы Гаджимөхәммәдовның Украинадагы батырлыгын искә алып: «...мин лаклы, мин дагыстанлы, мин чечен, ингуш, рус, татар, яһүд, мордвалы, осетин», – диде, руслар белән украиннарның да бер үк халык булуларын әйтеп, халыкларны тигез күрүен ассызыклады.

Көннең төп вакыйгасы, әлбәттә, ике ил делегациясенең очрашуы булырга тиеш иде. Батырлык батырлык белән, әмма каһарманнарның үлеме (батырлык күрсәткән дагыстанлы һәлак булган инде) сөендерә алмый. Хәрбиләр дә кемнәрнеңдер баласы, әтисе, ире бит. Россиянең тышкы эшләр министры Лавров бу уңайдан шулай ук 3 март көнне һәрбер кеше тормышының бәһасез, һәрбер хәрби хәрәкәтнең, кызганычка, хәрбиләр арасында гына түгел, тыныч халык арасында да корбаннарга китерүен билгеләп үтте. Шуңа күрә икенче очрашуны без түземсезләнеп көттек. Газета хәбәрчесе мәгълүмат кырыннан күзен алмады. Бары тик кичке сәгать алты туларга 9 минут калганда гына делегацияләрнең үзара кул кысышуын күрергә насыйп булды. Россиянең Беларусьтагы илчесе Борис Грызлов белән украин сәяси эшлеклесе Давид Арахамия хәтта бер-берсенә җылы итеп елмайдылар да. Әмма якларның позицияләре бер-берсенә алай ук якын түгел иде шул. Россия ягы махсус хәрби операцияне ахырына кадәр алып баруны куәтләсә, Украина ягы брифингларда үзенең җиңүләре хакында хәбәр итә, Горловканы, Донбассны азат итү планнары белән яна, чит илләрдән үзләренә килгән ярдәм хакында сүз алып бара. Ике як та үзләрен җиңүгә якын дип саный, кыскасы. Андый шартларда зур килешүләргә ирешү кыен. Шуңа карамастан кечкенә генә булса да кара-каршы адымнар ясалды. Тынычлык турында дәүләтара килешүләр үк булыр дип берәү дә көтмәде инде, әмма кыска вакытка гына булса да утны туктату кирәк һәм әһәмиятле. Сөйләшүләр өстәле янында шуннан соң иркенләп утырып, елмаешып булыр иде.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Владимир ЖАВОРОНКОВ, Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары:

Хәзерге вакытта Татарстанда 208281 доза вакцина бар. Сайлау мөмкинлеге дә зур. «Спутник V» вакцинасы аеруча популяр. Вакцинаның беренче дозасын халыкның 81 проценттан артыгы алган. Ярты ел элек прививка кадатучыларның 30 проценты ревакцинация узган.

РОССИЯДӘ – БАЛАЛАР ТӘРБИЯСЕ

Әби белән бабай да кирәк. Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрдән: «Бала тәрбияләүдә кемнәр катнашырга тиеш?» – дип сорашкан. Кайберәүләр әлеге вазыйфа өлкән буын җилкәсенә дә төшәргә тиеш дип саный икән.

БАЛАНЫ КЕМ ТӘРБИЯЛИ?

44%...əти һәм әни генә

12%...әби-бабайлар

1%.....профессиональ бала караучы

Түләү җиңеләя

Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә ташламалы кредитлар буенча түләүләрне ярты елга кичектерү хокукы бирелә. Әмма бер шарты бар: килешү вакыты 2022 елда чыгарга тиеш. Документ нигезендә, 2022 елның 1 мартыннан 31 мартка кадәрге түләүләр, банк уңай карарга килгән очракта, алты айга кичектерелергә мөмкин. Кыска вакытка алынган ташламалы займнарны да түләү вакытын озайту күздә тотыла.

Ташламалы кредитлар бирү программасында катнашучы банкларга да ярдәм чаралары каралган. Әйтик, кыска вакытлы ташламалы кредитлар буенча ставканы субсидияләү күләме 100 процентка җиткерелгән. Моңа кадәр ул 80 процент булган.

Казанда Уеннар үткәрелми

Украинадагы хәлләргә бәйле рәвештә, 2023 елда Казанда Бөтендөнья Кышкы махсус олимпиада үткәрелмәячәк. «Без Казанда Уеннарның нәтиҗәлелеген, шулай ук спортчыларның, җәмгыятьнең иминлеген тәэмин итә алмаячакбыз. Аларның үткәрелмәве безнең өчен, Украинадагы, Россиядәге, гомумән, бөтен дөньядагы спортчылар өчен җимергеч тәэсир ясый. Уеннарның уңышлы үткәрелүе өчен Россиядә, бөтен дөнья күләмендә еллар буе эшләгән кешеләргә рәхмәтлебез. Уеннар әлегә уздырылмаса да, без бүген һәм киләчәктә махсус олимпиада программасы буенча эшләүне дәвам итү бурычын үз өстебезгә алабыз», – диелгән Уеннарны оештыручы – Special Olympics International оешмасы белдерүендә.

Исегезгә төшерәбез: Бөтендөнья Кышкы махсус олимпиада ул – акыл үсешендә үзенчәлекләргә ия булучылар өчен ярышлар. Анда 107 илдән мөмкинлекләре чикләнгән 2 меңнән артыграк спортчы катнашырга тиеш иде.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Мәгарәгә юл тотып...

Бер акыл иясе: «Эш безне өч яманлыктан коткара. Ул да булса эч пошу, гөнаһ һәм фәкыйрьлек», – дигән. Чыннан да кешене кеше итеп бары бер нәрсә генә тота. Ул да булса – хезмәт. Ходай эштән аермасын. Хезмәт беттеме, деградация, түбәнгә төшү, таш гасырына, мәгарәгә кайту башлана. Һәм шактый тиз. Берничә мең ел – карыйсың, шау-гөр килеп цехларда эшләп йөргән халык урынына агач башын бер көтү макака сырып алган. Чиныйлар, урын өчен тарткалашалар, ботактан ботакка сикерәләр... Сезгә ошыймы мондый сурәт?

Бик ошап бетмидер, әлбәттә. Тик шуңа таба бармыйбызмы? Тулысынча автоматлаштырылган линияләр, компьютер идарәсендәге технологияләр, роботлардан гына торган цехлар, конвейерлар, үзе генә йөрүче машиналар. Дөньяга ажгырып хезмәт дефициты килә. Бу исә товар дефицитыннан хәтәррәк. Киләчәкне фаразлаучы белгечләр – футурологлар шушы гасыр уртасында технологик яктан алга киткән илләрдәге халык атнасына җәмгысы 2–3 көн генә эшләячәк, диләр. Сәбәбе бер: ул илләрдәге хезмәт җитештерүчәнлеге шундый дәрәҗәгә җитте ки, эшләүче бер кеше эшләмәүче, бармакка-бармак та какмаучы бер яки берничә кешене, теләгәндә, бүген үк берсүзсез туендырып тора ала.

Туендыра ала, дию бик үк дөрес тә түгелдер. Хәзер үк күпмедер ашата һәм киендерә. Швед социализмын без еш мактыйбыз, андагы һәм башка шундый илләрдәге киң вә куәтле социаль программалар, яклауны кукләргә күтәрәбез. Тик менә андый җәмгыятьләрнең дә киреккмәгән яклары юк түгел икән бит әле. Сорыкортлык тәрбияли икән ич алар. Телисең икән, эшлисең, теләмәсәң – эшләмисең, бот күтәреп ятасың. Аларда эшләмичә дә җырлап яшәргә була. Беркем дә сине паразитлыкта гаепләми. Эшсезлек буенча пособиеләр, ягъни туләүләр тамак туйдырырга гына түгел, өске бөтәйтергә, хәтта күңел ачарга да җитә. Тик сорау туа: андый тормыш рәвеше дөресме? Мондый социаль яклау – ялкаулыкны яклау, әрәмтамаклар үрчету түгелме? Түшәмгә төкереп күпме, ничә ай, ничә ел ятарга була?

Бер, ике буын. Өченче буын, миңа калса, инде ярымдебиль булачак. Чөнки баш мие, андагы сырлар, нейроннары белән бергә, организмга бөтенләй кирәксез булып чыга. Организм кирәксез әйберне үзендә озак тотмый – атрофия башлана. Шведлар, норвегиялеләр шундый шартларда әле беренче буын гына яши. Тик, сөйләнүләренчә, беренче карлыгачлар күренә башлаган да инде: үз-үзләренә кул салу буенча алар беренчелеккә чыкты. Эшләмисең, физик яки акыл хезмәте белән тәнне, җанны ныгытып, канатлык алып яшәмисең икән, беренче булып аренага рухи чирләр, шул исәптән депрессия килеп чыга. Ул тирәнәеп киттеме – дөнья белән инде саубуллаша башла. Рухи чирең чыкмаса, томаналана тор, кыргыйлан. Тәмам макака халәтенә җиткәнче. Дарвин теориясе кире якка да эшләми дип кем әйтә ала?

Адәм баласы шундый: ул болай да, эшләп торганда да, комфорт, уңайлыклар дип кыбырсый. Азрак кыймылдарга, артыгын уйланмаска, күбрәк кызык эзләргә маһир без. Нәфес һәм ялкаулык – төп идарәчеләр. Тик без бик каты алданабыз. Без ашкынган уңайлыкларның күбесе – башны эшкә җикмәү, хәрәкәтсезлек, ялкаулык чыганаклары. Телевизор пультыннан башлап автомобильгә чаклы. Юк, сүз адәми затның сәламәтлеген урлап торучы бәлаль гиподинамия турында гына түгел. Гиподинамиядән башка да елдан-ел медицинага, дарулярга бәйлелек артып тора. Эшләмәгәндә, алда әйтелгәнчә, физик саулыкка бәйле акыл, рух сәламәтлеге дә кирегә тәгәри. Ул процесс бүген үк бара инде. Китап укырга иренгән, дөньяны компьютер экраны аша гына күргән тулы бер буын үсеп җитешмәдеме? Аларга кызыгып түгел, кызганып карарга кирәктер.

Без бушка килгәнне, халяваны бик яратабыз. Эшләмичә генә, эшсезлек өчен, мәсәлән, 30–40 мең сум акча алып яткан кеше үзен коммунизмда итеп хис итәчәк. Атнасына ике генә көн эшләгән зат та нәкъ шулай. Тик бу – буш канәгатьлек һәм ясалма шатлык. Азу! Ә пособие исә – социаль наркотик. Дәүләт бу очракта наркотик өләшүче булып чыга. Ул наркотикта күпмедер утырганнан соң адәми затта эшләү теләге тулысынча юкка чыга. Теләсә нинди наркотик – иртәме-соңмы, тормышның төбенә төшү, бетү ул. Ә бит организмның үз, табигый наркотигы – эндорфиннары бар. Нәкъ шул матдә күңелгә хуш килгән физик яки акыл хезмәтеннән соң, кызыклы әңгәмәдән, яхшы китаптан соң баш миендә ярала да табигый рәхәтлек, канәгатьлек китерә. Ә «homo sapiens» дип аталучы «аңлы» зат аңа гына риза түгел.

Антик чорның мәшһүр империясе – Рим ни өчен юкка чыккан дип уйлыйсыз. Эшләмичә, күңел генә ачып, рәхәтлеккә генә яшәгәнгә. Провинцияләр эшләгән, колләр көне-төне авыр хезмәттә җәфа чиккән, ә элита, патрицийлар, ирекле гражданнар дип аталган катлауга чаклы ашаган һәм күңел ачкан, оргияләргә бирешкән. Нәтиҗәдә яшәү көче – пассионарлыктан берни дә калмаган. Римлылар кыргыйга, кеше булып җитмәгән җаннарга санаган варварлар «продвинутый» цивилизациянең башына җиткән дә куйган.

Бүгенге «продвинутый»лык – техникага салышып, үзеңне уңайлыклар белән урау. Техник алгарышның ахыр максаты – табыш һәм комсызлык аясә хәрби өстенлек. Техника үсеше, янадан-яңа технологияләр уйлап табу, дигәндә, Җир йөзендә меңнәрләгән институтлар, лабораторияләр эшли. Ярыш бара. Ә иманны, әхлакны арттыру җәһәтендә фәнни тикшеренүләр, проектлар бөтенләй дә юк. Чөнки андый алгарыш кесәне калынайтмый, нәфесне канәгатьләндерми. Кире эффект туып, иганәчегә әйләнсәң, мохтаҗларга ярдәм итә башласаң, иманың артса, нишләрсең?!

Бәндәне иман, әхлак кысаларында тоту, яхшыргу максатыннан кешелек күптән уйлап тапкан бөек казанышы – дин, аны тоту, аның белән саклашу да бүген ташка үлчим. Бүген без – оҗмахка да, тәмугка да, Аллага да, мулалага да ышанмаган тәэлмәс атеистлар һәм дә материалистлар. Без технологияләр дип шашынган арада, акыл үсеше туктап, мидәге сырлар кимеп бармыймы? Эшләргә генә түгел, уйларга да иренә башламадыкмы? Безнең өчен инә техника, компьютерлар уйласын димибезме? Һәрхәлдә, икенче бер акыллы затны кабатлап: «Дөнья кирегә китмәгәндә дә, алга таба бармый, ул бары үзгәрә генә», – дип әйтү дөрес, ахрысы.

ЯЛГАН ТАРАТУЧЫЛАРГА КӨН БЕТӘ

Ялган хәбәр таратучылар 15 елга кадәр төрмә җәзасына дучар ителергә мөмкин. Дума Россия армиясенең дәрәҗәсен төшерүче фейклар һәм илебезгә каршы санкцияләр кертүгә өндәүләр өчен җинаять җәзасын яки зур күләмдә штрафларны күздә тоткан закон проектын соңгы укылышта кабул иткән.

Документта билгеләп үтелгәнчә, ялган хәбәр тараткан өчен 15 елга кадәр төрмә җәзасы билгеләнергә мөмкин. Фейк авыр нәтиҗәләргә китергән очракта әнә шундый иң кырыс җәза чарасы кулланылачак.

Фейк өчен штрафлар да зур булачак. Россия Кораллы көчләре турында белә торып ялган мәгълүмат тараткан өчен 700 мең сумнан 1,5 миллион сумга кадәр яки хөкем ителученең соңгы 18 ай эчендәге хезмәт хакы яисә башка кереме күләмендә штраф; бер елга кадәр төзәтү эшләре; өч елга кадәр мәҗбүри эшләр; өч елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган.

Хезмәт урыныннан файдаланып, тегеяки бу зат (бер төркем кешеләр), үзара килешенеп, ясалма гаепләү дәлилләре булдырып, үзенә файда алу, сәяси, идеологик, раса, милли яки дини нәфрәт, бәрәр нинди социаль төркемгә нәфрәт белдерү яки дошман күрү сәбәпле җинаять кылган очракта, матди җәза 3–5 млн сумны тәшкил итәчәк. Шулай ук хөкем ителученең 3–5 еллык чордагы хезмәт хакы (яки башка кереме) күләмендә штраф салу, билгеле бер вазыйфаны биләү хокукыннан мәхрүм итеп (яки биш елга кадәр билгеле бер эшчәнлек белән шөгыльләнүне рөхсәт итмәү), биш елга кадәр мәҗбүри эшләргә тарту яисә 5–10 елга кадәр иректән мәхрүм итү күздә тотыла.

Закон проектында Россиягә каршы санкцияләр кертүгә өндәү өчен җәза чаралары да каралган. Моның өчен 500 мең сум яки хөкем ителученең өч елга кадәрге чордагы хезмәт хакы яки башка кереме күләмендә штраф; өч елга кадәр иректән мәхрүм итү; өч елга кадәр мәҗбүри эшләргә тарту; алты айга кадәр кулга алу; 3 елга кадәр иректән мәхрүм итү, ике йөз мең сумга кадәр яки хөкем ителученең бер елга кадәрге хезмәт хакы яисә башка кереме күләмендә штраф билгеләнергә мөмкин.

Россия армиясенең дәрәҗәсен төшерүгә өндәүләр өчен иң зур җәза чарасы – 5 елга иректән мәхрүм итү.

Вакыт отарга тырышу файдага түгел

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Россия делегациясен җитәкләгән Мединский: «...тыныч халыкка чыгу өчен коридорлар форматы һәм коридордан халык чыккан урыннарда хәрби хәрәкәтләрне вакытлыча туктатып тору турында килештек. Моны зур алга китеш дип саныйм», – диде. Моңа өстәп Дәүләт Думасының комитет рәисе Слуцкий әфәнде хәрби ведомстволарга әле коридор оештыру механизмын билгеләргә кирәк булачагын да әйтте. Киев вәкиле Михаил Подоляк гуманитар мәсьәләләрнең тикшерелүен таныды, әмма «исәп тоткан нәтиҗәләргә килә алмаулары»на үкенеч белдерде.

Сөйләшүләрнең яңа раунды киләсе атна башында дүшәмбе көнне булыр дип ниятләнә. Өч-дүрт көн вакыт эчендә яклар икесе дә үзләре файдасына зур үзгәрешләр булыр дип өметләнә, аяк терәп сөйләшү өчен яңа җиңүләр тели.

Көн саен корбаннар арту гына түгел, икътисади хәл дә начарая. Россияле миллиардер Дерипаска кризиска: «...1998 елгы кризисны алабыз да өчкә тапкырлыйбыз», – дип бәя бирде. Аның сүзләрен «Собеседник» атналыгы китерә. Газета хәбәрчесе өенә капчыклап он китертә алмады, даими рәвештә азык-төлек белән безне тәэмин итеп торучы эшмәкәр «онны капчыклап алып кайтып булмый» дип зарланды, дүшәмбе көнне базага барып карарга вәгъдә бирде. Кичә Арча кибетләрендә йөрдем, паника юк, кием-салымны арзанга гына алып була, вәләкин компьютер техникасы сатыла торган кибеттә: «Әлегә берни дә сатмыйбыз», – диделәр. Киштәдә ноутбуклар моңаеп утыра, бәяләре куелмаган.

Кризис безнең генә түгел, европалыларның да киргән бирә. Анда газга һәм электрга бәяләр кушаяклап үргә чаба. Макрон: «Бензинга, газга һәм иң кирәкле товарларга бәяләр үсү безнең сатып алу мөмкинлегенә тәэсир ясый», – дип белдерде милләткә мөрәҗәгатендә. Газета хәбәрчесе Бөекбританиядән бер таксистның: «Соңгы атнада бар нәрсәгә дә бәяләр күккә ашты. Электр энергиясенә түләүләр котны алырлык», – дигән хәбәрен алды. Шуңа карамастан Европа илләре җитәкчеләре Россия газы һәм нефтеннән баш тарту сәясәтен алып баралар. Сөйләшүләрнең өченче раундын түземсезләнеп көтәбез, чөнки бөтен дөньяда хәл начарая. Кытай – Америка мөнәсәбәтләрендә дә киеренкелек арта. Боларның барысының да нәтиҗәләре безнең тормышка коронавируска караганда да зуррак тизлек белән үргылып керәләр. Вашингтоннан: «Россия гаскәрләрен алса, санкцияләрне туктатыр идек», – диган тавышлар да ишетелә. Бездә шактый сайтлар эшләми, Россиянең кайбер мәгълүмат чаралары да бикләнде. Без зарланмыйбыз, вакыт шундый, тормыш шундый, ләкин кичәге көннәрнең иркенлегенә булса да кире кайтуны тели күңел. Ике ил делегациясенең сөйләшүләренә бик күп нәрсә бәйле. Шуңа күрә ике якка да компромисслар телибез. Дуслык җиңсен иде, без бит дошманнар түгел.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Нәтиҗә

ТӨЛКЕНЕ КИМЕТЕРГӘ, БОЛАННЫ ҮРЧЕТЕРГӘ

Узган ел республика юлларында кыргый хайваннарны таптатуга бәйле 150 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән. Машина астына барыннан да бигрәк поши, кабан дуңгызы, кыр кәҗәсе эләгә икән. 2021 елда 45 кабан дуңгызы, 95 поши, 25 кыр кәҗәсе, 2 марал машина астында калган.

Аварияләрнең күбесе Питрәч, Алабуга, Азнакай, Әлмәт районнарында килеп чыккан. Бу хакта Татарстанның Биоресурслар буенча дәүләт комитетының еллык киңәйтелгән утырышында әйтелде. Озакламый юлларда кыргый хайваннар тапталуын булдырмас өчен «Экотор» дип аталган яңа система эшли башлаячак. Бу хакта Татарстанның Биоресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе Федор Батков җиткерде.

– 2020 ел белән чагыштырганда, узган ел юлларда һәлак булган кыргый хайваннарның саны 20 процентка артып китте. Әлегә һәлакәтләр машина йөртүченең гомерен дә куркыныч тудыра. «Экотор» системасы, хайваннарга куркыныч янаганда, аларны сигнал биреп куркытачак. Шул рәвешле, хайваннар машина юлына керми калачак. Әлеге системаны урнаштырганда шулай ук аларга махсус җир астыннан һәм күперләр аша юлны чыгу мөмкинлеге дә тудырылачак, – ди Федор Батков.

Үлгән хайваннар саны куркытса да, ел дәвамында үрчүчеләр дә күп булган. Безнең якларда поши, куяннар артып киткән. Тагын бер сөенечле хәл: республикада ике яңа төр хайван үрчи башлаган.

– 1970 елда безгә кабаннар кайткан иде. Ничә елдан соң бездә марал һәм тамгалы боланнар үрчи башлады. 2030 елга кадәр без әлеге төр хайваннарны бөтен республикага таратмакчы булабыз. Хәзерге вакытта республиканың 16 районында 500 баш тамгалы болан яши. Татарстанның Кама арьягында хайваннарның күплән үрчүе күзәтелә. Аеруча соры куян, көртлек һәм суерлар артты. Шуңа аларның кайбер төрләрен киметү максатыннан ау өчен рөхсәт кәгазьләрен бирүне арттырырга кирәк. Ачулар өчен рөхсәт бирүнең бәясен киметү дә карала, – ди комитет җитәкчесе.

Федор Батков хайваннар арасында таралган авыруларга да тукталды. Африка чумасы аркасында кабаннарның баш санын киметкәннәрен дә әйтте. 2020 елда республикада 6 мең баш кабан булса, узган ел аны 900гә калдырганнар. Төлкеләр белән шул ук хәл. Котыру чире аркасында аларны да киметү эшләре бара. Узган ел 3 мең баш төлкене харап иткәннәр. Әмма әле дә комитетка, авылда төлке йөри, дигән хәбәр еш килә икән. Федор Батков аучыларга төлкеләрне дә киметү бурычын куйды.

Утырышта табигать байлыгына зыян салучы браконьерлар хакында сүз булды. Узган ел законсыз ау өчен 89 җинаять эше ачылган. Табигатькә 7 миллион сумлык зыян килгән. Законсыз кулланышта булган 32 ау коралын алганнар.

Федор Батков күп документларның дәүләт порталы аша алып булганын әйтте. Быел бу эшне тагын да киңәйтәчәкләр. Ел ахырына барлык дәүләт хезмәтләре электронлашып бетәчәк. Утырышта аеруча саклана торган территорияләр хакында да сүз булды. Республикада бу юнәлештә зур эш алып барыла. Татарстанның Биоресурслар буенча дәүләт комитеты КФУ галимнәре белән тыюлыктагы хайваннарның, үсемлекләрнең санын ала. Араларында Кызыл китапка кертелгәннәре дә бар. Кышкы исәпләү турында да сөйләделәр. Әлегә хайваннарның һәм кошларның эзен санап, аларның күләмен белү эше тәгәлләнмәгән. Март ахырында төгәл саннар билгеле булачак.

Татарстанның Премьер-министр урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин Биоресурслар буенча дәүләт комитеты эшчәнлегенә уңай бәя бирде. Узган ел ул аеруча саклаучы территорияләрнең чикләрен билгеләү эшен башкарырга кушкан булган. Комитеттагылар әлеге эшне тәмамлый икән инде.

– Быелдан ау билетларын бирү дә катлауланды. Белемне тикшереп тапшыралар хәзер. Республика сулыклары да сезнең өстә. Балыкларга кислород керсен өчен бозны тишкәндә кул хезмәте кулланыла. Әнә шуны җиңеләйтер өчен махсус җиһаз кирәк, – диде ул. – Күп эшләрегез электрон башкарыла. Хайваннар санын алу да онлайн теркәлә икән. Бу вакытны янда калдыра. Цифрлаштыру елы уңаеннан, бу эшне дәвам итәргә кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

МАРАТ ҖӘББАРОВ:

«ҮЗЕБЕЗДӘ ЯСАЛГАННЫ КАРЫЙК»

Авыл хуҗалыгы

Кызганыч, Көнбатыш илләр керткән санкцияләрнең авыл хуҗалыгына да йогынтысы зур булачак. Инде базарда техникага һәм запас частьларга кытлык барлыкка килгән. Җитмәсә, алда зур бурычлар һәм максатлар тора. Тиздән аграрийлар кыр эшләренә керешергә тиеш. Ә аны берничек тә чигереп булмый. Фермер, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясенең XXII съездында авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров фермерларга әнә шундый борчулы хәбәрләр җиткерде.

tatarstan.ru

Министр әйтүенчә, министрлык үзебездә ясала торган запас частьлар, машиналар һәм җиһазлар турында мәгълүмат җиткереп тора. Шулай ук кайтарылырга тиешле товарлар да җитди күзәтү астында булачак.

– Республика чәчүлек орлыклары белән тулысынча тәэмин ителгән, – диде Марат Җәббаров. – Шул ук вакытта шикәр чөгендере, көнбагыш һәм кукуруз орлыклары контракт буенча чит илдән кертелә. Алар белән 85–90 процентка тәэмин ителде. Орлыкларның бер өлеше чит илдә, аларны кайтару белән тоткарлыклар булырга мөмкин. Шикәр чөгендеренең чит ил һәм гибрид сортларын алып кайту белән проблемалар булуы бар. Икенче проблема да килеп чыгарга мөмкин – долларның тотрыксыз булуы аркасында, бәяләр арта. Орлык белән тәэмин итучеләрнең алдан ук аларның тулы бәяләрен сораулары бар. Шуңа күрә кабаттан алар белән элемтәгә кереп, сөйләшеп бетерегез.

Министр шулай ук инкубация йомыркалары һәм төрлекек колларда белән тәэмин ителешкә, савым залларындагы чит илләрдән кайтарылган запас частьларга да зур игътибар бирергә кирәклеген әйтте.

– Күпчелек ветеринария препаратлары чит илдән кайтарылган, үзебездә җитештерелгән аналогларын кулланырга кирәк, – дигән бурыч куйды Марат Җәббаров.

Авыл хуҗалыгы министры урынбасары Ришат Хәбипов чарадан соң «ВТ» хәбәрчесенә белдерүенчә, эшләр бүгенге вазгыятькә карап оештырылачак.

– Беренчедән, мөмкинлек булганча, җиһазларны, запас частьларны үз илебездә ясалганнар белән алыштырырга кирәк булачак. Бездә барлык мөмкинлекләр дә бар. Икенчедән, шикәр чөгендере, кукуруз уңышы, бәлки, азрак булса да, барыбер Татарстанда җир чәчелми калыр дигән курку юк. Халыкны азыктөлек белән тәэмин итү – министрлыкның төп бурычы. 2022 ел уңышына зур өметләр баглыйбыз. Әзерлек җитди бара, – диде Ришат Хәбипов.

Съездда төп доклад белән чыгыш ясаган фермер, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе президенты Камияр Байтемиров әйтүенчә, узган ел фермер хуҗалыкларының тулай төбәк продукты – 23,6 млрд сум, шәхси крестьян хуҗалыкларыныкы – 98,2 млрд сум, кооперативларныкы 8 млрд сумнан артык тәшкил иткән. Бу – республика җитештергән гомум продукциянең 51,3 проценты дигән сүз.

Шул ук вакытта фермерлар көн саен очрашып тора торган авырлыклар да җитәрлек. Алар арасында җир алу һәм рәсмиләштерү белән бәйле проблемалар, кредит алудагы, авылларда җитештергән продукцияне сату кебек авырлыклар беренче урында тора.

– Кайбер районнарда фермер хуҗалыклары махсус рәвештә үстермиләр. Бүлеп бирелгән җирләрне бирмиләр, алда арендага бирелгәнне төрле сәбәпләр табып тартып ала башлыйлар. Монда хәтта хуҗалыклар керткән чыгымнарны да искә алмыйлар, – диде Камияр Байтемиров.

Шулай ук ул минераль ашламалар, ягулык-майлау материаллары, үсемлекләрне корткычлардан саклау, металл, төзү материалларына бәя артуны да әйтте.

– Моннан тыш, фермер хуҗалыкларын ничек кенә тикшермиләр, фермерның һәр хәрәкәтен әйтеп торучы цифрлы системалар (ФГИС «ЗЕРНО», «ЦЕРБЕР», «МЕРКУРИЙ», продукцияне маркировкалау) кертәләр. Дәүләт исеменнән таләп ителгән кагыйдәләр кайбер хуҗалыкларның мөмкинлекләре белән бөтенләй туры килми, – диде баш фермер.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

СУЛКЫЛДАП ЕЛАДЫМ, ШАРКЫЛДАП КӨЛДЕМ

vk.com

Остазым, консерватория профессоры, күренекле опера җырчысы Зөләйха апа Хисмәтуллина

Консерваториядә уку елларымны хәтеремдә яңарта башласам, кылт итеп Зөләйха апа Хисмәтуллина күз алдыма килеп баса. Ул – гомерен җыр сәнгатенә, аны үстерүгә багышлаган олуг шәхес, бик күпләрнең, шул исәптән минем дә остазым. Ул үзе – консерватория профессоры, шул ук вакытта күркәм, кабатланмас, самими тавышка ия опера җырчысы иде, аннан өйрәнделәр, аннан үрнәк алдылар. Шушы тавыш радио аша Сарман урманнары эченә кереп урнашкан туган авылыбыз халкын да җәлеп итте. «Кызыл төлке»се генә ни тора иде аның, җырны тыңлаган саен тыңлыйсы гына килеп торды. «Җырласаң, менә шушы апа кебек җырларга кирәк», – дия идем мин үземә. Ходайның рәхмәте, язмыш мине – авыл кызын радио тәлинкәләреннән җырын тыңлаган шушы апа белән очраштырды. Консерваториянең вокал бүлегендә нәкъ менә аның классында укый башладым. Шатлыктан бәхетнең җиденче күгендә идем. Аның классына элэгүем дә һич кенә дә очраклы булмаган икән. Монысын инде мин соңрак аңладым. Консерватория ректоры Нәҗип абый Җиһанов кабул итү имтиханнарында үзе дә катнаша торган булган һәм мине тыңлаганнан соң, бу кыз һичшиксез консерваториядә белем алырга тиеш, дигән фикергә килгән. Соңрак Нәҗип абыйның үзенең дә сөйләгәне булды: «Без сине сынап карау ниятеннән укырга алдык», – дигән иде ул. Сынап карау? Сер түгел: консерваториядә сопрано – иң югары, нечкә тавышларга өстенлек бирелә, бу уку йортында опера һәм опера-камера җырчылары әзерлиләр иде.

Миндә исә – халыкчан тавыш. Зөләйха апа янына да мин икеләнеп кердем, аннан: «Юк, мин Сез таләп иткәнчә, алар җырлаганча җырлый алмыйм», – дидем һәм үзем дә сизмәстән, күзләрем яшьләнде. «Ник елыйсың?» – дип сорады апа. «Алар җырлаганча җырлый белмим», – дип кабатладым. «Исең киткән икән, – диде укытучыбыз. – Алар күбәү, син берәү генә. Син халыкчан җырчы булырсың, концертларда катнашырсың. Мин синең тавышың өчен җаваплы».

Зөләйха апа уку дәверендә миңа үтә игътибарлы булды. «Синең тавышың киңәячәк әле», – дип үсендерә иде. Ул җырлау нечкәлекләренә өйрәтте, дәресләрне зур түземлек белән, үтемле итеп махсус вокал күнекмәләре үткәрүе хәтеремдә калган. Җырчы булу теләге миндә көчәйгәннән-көчәя генә барды. Тавышларын югалтучыларга ул «дәвалау» дәресләре дә үткәрә иде. Мин – беренче мәлләрдә аның янында елап утырган кыз бала, соңга таба аның дәресләрендә үземне тыя алмыйча шаркылдап көлә идем. Зөләйха апа, гаҗәпләнеп: «Ни булды?» – дип куя. «Безнең авылда сыерлар нәкъ минемчә мөгри, аннан тамакларын ертып бөтен авылны дер селкетә, шуны искә төшердем», – дидем мин. Зөләйха апа үзе дә сизмәстән, рәхәтләнеп елмаеп алды: «Чагыштыруың мәгънәле синең. Сыер ул бик матур һәм дөрес мөгри. Зөһрә акыллым, сиңа монда вакыт-вакыт сыер да, әтәч тә, сарык та булып карарга туры киләчәк. Елаудан да, көлүдән дә тартынма: шушы халәтләрдә дә җырга бирелеп китү бик еш күзәтелә».

Зөләйха апа безгә һәрьяктан үрнәк иде. Җаваплылык дигән төшенчә аны гомере буе озата килде. Бик яхшы хәтерлим: опера һәм балет театрында «Аида» операсы куелыр көн якынлашты. Зөләйха апабыз анда төп рольне – Аиданы башкара. Әмма апабыз авырып китте, аны алыштырырлык кеше әзерләнмәгән һәм ул юк та. Барыбыз да бик борчылдык һәм сәхнәдә могҗиза күзәтелде: тамаша үтә җылы кабул ителде, апабызның бер тавыш җепсельләре белән генә җырлавын сизмәделәр дә, белмичә дә калдылар. Икенче көнне врач-фониатр Флера апа Таһированың: «Зөләйха Гатаулловнаның тавыш җепселләре корычтан», – дип бәяләвенең шаһитлары идек. «Катерина Измайлова» операсы булган көнне Казанга аның авторы, бөек композитор Дмитрий Шостаковичның махсус килүе дә күп нәрсә хакында сөйли. Төп рольдә исә Зөләйха апа иде.

Зөләйха апада белем алуым белән мин бик бәхетле. Хәер, бу урында, без, дип күплек санында әйтү кирәк. Бик күпләрне ул тыңлау серләренә, нечкәлекләренә, халкыбызга хезмәт итәргә өйрәтте, шул рәвешле татар җыр сәнгатен баетты, үстерде. Ул гаиләләребезнең дә дусты, киңәшчесе иде, ярдәмен дә тоеп гомер иттек. Берара без алар белән театр әһелләре йортында да яшәдек. Бала тудыру йортыннан нәниебезне алып кайтырга Хәйдәр белән бергә Зөләйха апа да килгән иде. Алай гына түгел, ул безне кунакка чакырды, әтиәни булу хөрмәтенә өендә сый өстәле дә әзерләгән иде. Кисәк кенә Хәйдәр авырып киткәч, шифалы үләннәр ваннасы әзерләп кунакка чакыруы да хәтеремдә, өстәлендә исә сый-нигъмәт булыр иде.

Талантлы музыкант Рәшит абый Таймасов белән алар бик матур гомер кичерде, әмма хәләл җефетенең гомере генә кыска булды. Сагынды, бик сагынды Зөләйха апабыз, эч серләрен без – укучылары белән дә бик теләп уртаклаша, шуның белән күңеленә бераз җылылык тапты булса кирәк.

Остазым, консерватория профессоры, күренекле опера җырчысы, тәрбияче, мәрхәмәтле әни – Зөләйха Хисмәтуллина дигән шәхесебезне бәяләү өчен сүзләр дә табып бетерә алмыйм: шунысы хак – ул буй җитмәслек биеклектә иде. Күңелләрдә шулай саклана да.

Зөһрә СӘХӘБИЕВА,
Татарстанның халык артисты

Мунча Хөрмәте

Балачак Балтач төбәгендәге авылда узды. Хатирәләргә мунча керү дә кереп калган. Мунча һәр атна ягыла иде. Анда юынып кына калмыйсың, әти шунда елата-елата чәчне дә кырып ала, йөрибез аннан кояш кебек ялтырап. Әни: «Рәхмәт мунча хөрмәтенә дип әйтү тиеш», – дип өйрәтте. Балачакта ияләнгән гадәт шәһәрдә яшәүгә күчкәч тә дәвам итте: ванналы, душлы фатирда яшәсәм дә, һәр атна мунчага йөрим. Күп кеше авыл мунчасын мактаса да, мин: «Авыл мунчасын макта, шәһәр мунчасына йөр», – дигәнрәк фикердәмен. Чөнки авыл мунчасында чабынсаң, юынырга эссе, кабат-кабат чабыну, юыну авырга туры килә. Яшь барган саен бу үзен нык сиздерә. Шулай да балачакта авыл мунчасындагы рәхәтлекне һич онытасым юк. Мунчага якшәмбе көнне барырга күнеккәнмен. Соңгы баруымда урыннар бик мөлаем, сүзчән, урта яшьләрдәге ир-егет белән туры килде. Ул да авылда үскән, хәзер шәһәрдә яши икән. Исеме – Хөрмәт. Менә бит, рәхмәт яугыры, бу нәкъ үзе – мунча Хөрмәте була түгелме соң инде?

«Кара урман»да адашу

Үткән гасырның сиксәненче елларында мин хәрби хезмәттән кайтканнан соң «Татагропромстрой» идарәсенең торак-коммуналь конторасында эшләдем. Җитәкчебез Николай Архипов бәйрәмнәр ярата иде, сыйландык, рәхәтләнеп күңел ачтык. Мин гармунда уйныйм. Соңрак аның үзенең дә гармунда уйнарга һәвәслеген белдем. Шулай бер мәҗлескә дустын да алып килде. «Бу дустым бик матур итеп җырлый, өстәвенә шәп кеше, исеме – Әюп», – дип таныштырды. Утыра торгач, Әюп җыр сузды. «Иске кара урман» җыры иде ул. Сузыпмы-суза, тын да алмый тыңлыйбыз. Җырлый торгач, абзыебыз да чынлап торып «Кара урман»га кереп «адашкан» кебек булды, беркемне күрми, беркемне ишетми башлады. Халык аптырап калды, пышылдаша башладык. Кунагыбыз тирләп чыкты һәм, ниһаять, җырлавыннан туктады. «Йә, ничек?» – диде ул. Без гөрләтеп кул чаптык, әмма тагын җырлагыз, тагын җырлагыз, дип үтенү ягында түгел идек инде. Өйләргә таралышасыбыз бар, анда да эш җитәрлек, гел җыр гына димәгән, җырлап тамак туймас…

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН

ИСТӘЛЕК

Өч фитильле керосин плитәсе безнең гаиләдә җитмеш елга якын саклана инде. Әтиебезгә Мәскәүдә, СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә биргән булганнар. Әтнә районының «1 нче Май» колхозы бригадирының хезмәттәге уңышларын менә шулай бәяләгәннәр һәм плитәдән бик озак файдаландык, баллонлы газ плитәсенә күчкәнче тугыз кешелек гаиләне туендырып торды ул.

Җитмеш елга якын эш стажы булган әтиебезнең истәлеге әле дә кулланугa яраклы: керосин саласы да шырпы сызып кабызып кына җибәрәсе.

Мансур ХУҖИЕВ

Яңа елны биеп каршыладык

Сиксәненче еллар азагында Фиргат Беляев белән Яңа ел бәйрәменә Урта Йорткүлгә чакырдылар. Анда бераз утырырбыз да төнге сәгать уникe тулганчы авылга кайтып җитәрбез, дигән уй белән Чәчәкле мәктәбенең «ГАЗ-52» машинасын кабызып (директор Әнвәр абыйга әйтеп тормадык), чыгып киттек.

Болай ярыйсы гына кунак булдык. Унбер тулгач, кайтырга чыктык. Ул ел кышы галәмәт салкын булды. Машинаның миче юньләп җылытмаганга, алгы тәрәзә бозланып катты, юньләп берни күренми. Лобовка авылы тирәсеннән узып, «Звезда» колхозы территориясенә кереп тә җитмәдек, машинабыз юл читендәге карга яны белән төште дә ятты. Котыбыз очты! Кабина яртылаш кар эчендә калды. Көч-хәл белән капотны ачып, радиатордагы суны агыздык, юешләнеп туңып беттек.

Кулдагы сәгатькә карадым – төгәл уникене күрсәтә. Әнә шулай кыр уртасында басып калдык. Салкынга чыдарлык түгел, аяк-кулларга үтә. Ичмаса, юлда узгынчы машиналар да күренми. Башта Фиргат белән күктәге йолдызларны санаган идек, аннары аякларны тыпырдатып биергә керештек. Иртәнге бишләргә кадәр йөгереп тә, биеп тә туйдык. Аннары Кузнечиха маслозаводына киттек. Фәрит абый Хөсәенов тракторы белән көчкә сөйрәп чыгарды. Авылга кадәр дә ул артына тагып менде.

Тәлгат МАНСУРОВ

Белдерү

Кадастровым инженером Биктимировым Ильшатом Ринатовичем (почтовый адрес: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д. 1, контактный тел.: 89600482408, электронная почта: biktimirov_i@mail.ru, № квалификационного аттестата 16-10-80), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:060404:1, расположенного по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, ул. Бухарская, выполняются кадастровые работы по уточнению границ земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Шафигуллин Ильшат Ирекович (почтовый адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Школьная, д. 20).

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться в будние дни с 10.00 до 18.00 ч. по адресу: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д. 1.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ земельного участка состоится по адресу: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д.1 6 апреля 2022 года в 10 часов 00 минут.

Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются со дня опубликования в печатном издании в течение месяца по адресу: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д. 1.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы земельного участка: 16:50:060404:4; 16:50:060404:12; 16:50:000000:645; 16:50:060404 (земли общего пользования).

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ ЗЕМЕЛЬНЫХ УЧАСТКОВ

Кадастровым инженером Фахразиевым Илфатом Рашитовичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-261, с 03.05.2012 г. состоит в СРО Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья, реестровый номер 0028), адрес: 423445, РТ, Альметьевский район, д. Новокаширово, ул. Гагарина, д. 7, кв. 2. Тел.: 89179335383, email: ooo_stelscom@mail.ru, подготовлен проект межевания земельных участков, выделяемых в счет земельной доли Баширова Рената Рафиловича, общей площадью 15,6 га., Гильманова Асхата Нурутдиновича, общей площадью 5,2 га., Насыбуллина Анаса Галиевича, общей площадью 5,2 га., Ахметовой Миляуши Исхаковны, общей площадью 5,2 га., Башировой Асии Шигаповны, общей площадью 5,2 га., Хикматова Абдуллы Ярулловича, общей площадью 5,2 га., Акрамовой Гульшат Рафиковны, общей площадью 5,2 га., Акрамова Фирдаус Мансуровича, общей площадью 5,2 га., из земельного участка с кадастровым номером 16:08:000000:40, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Апастовский муниципальный район, Верхнеаткозинское сельское поселение.

Заказчиком работ является Баширов Ренат Рафилович (Республика Татарстан, Апастовский муниципальный район, с. Карамасары, ул. Рахман Ильяса, д. 81. тел.: 8-9274206516).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, Альметьевский муниципальный район, г. Альметьевск, ул. Герцена, д. 88, пом. 1038/1, офис ООО «СтелсКом».

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.*

*п. 8, п. 11 ст.13.1 Федерального закона от 24.07.2002 г. № 101-ФЗ «Об обороте земель сельскохозяйственного назначения».

Сафиной Алсу Азатовной – кадастровым инженером АО БТИ РТ (номер квалификационного аттестата кадастрового инженера 16-10-772, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. П. Коммуны, д. 8, 420030, lil_kalsyy@mail.ru, тел.: (843) 5575483, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляемых кадастровую деятельность 33596) проводятся кадастровые работы в отношении земельных участков, расположенных по адресу: Республика Татарстан, Пестречинский муниципальный район, Ленино-Кокушкинское сельское поселение, НСТ «Энтузиаст», участок № 204 с кадастровым номером 16:33:100908:20, Республика Татарстан, Пестречинский муниципальный район, Ленино-Кокушкинское сельское поселение, НСТ «Энтузиаст», участок № 205 с кадастровым номером 16:33:100908:45, Республика Татарстан, Пестречинский муниципальный район, Ленино-Кокушкинское сельское поселение, НСТ «Энтузиаст», участок № 203 с кадастровым номером 16:33:100908:19.

Заказчиком кадастровых работ является Кастрикина Елена Павловна (контактная информация: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Парижской Коммуны, д. 8. Тел.: 5575483).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. П. Коммуны, д. 8, каб. № 209, АО БТИ РТ 7 апреля 2022 г. в 10.00 ч.

С проектом межевого плана можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. П.Коммуны, д. 8, каб. № 209, АО БТИ РТ.

Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 6 марта 2022 г. по 6 апреля 2022 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 6 марта 2022 г. по 6 апреля 2022 г. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. П. Коммуны, д. 8, каб. № 209, АО БТИ РТ.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:33:100908:16 (Республика Татарстан, Пестречинский муниципальный район, Ленино-Кокушкинское сельское поселение, НСТ «Энтузиаст», участок 206).

При проведении согласования местоположения границ при себе иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

КОТЛЫЙБЫЗ!

Спорттагы югары казанышлары, 2022 елда Пекин шәһәрендә (Кытай Халык Республикасы) узган XXIV Кышкы Олимпия уеннарындагы җиңүгә ихтыяр көче, ныклыгы һәм максатка омтылышлылыгы өчен «Татнефть-Ак барс» спорт-коммерция предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте спортчысы-хоккейчы **Билалов** Тимур Рафаэль улы, «Татнефть-Ак барс» спорт-коммерция предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте спортчысы-хоккейчы **Воронков** Дмитрий Сергеевич **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» I дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Халык сәламәтлеген саклау эшенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе ультратавыш диагностикасы бүлекчәсе мөдире – нурланыш ярдәмендә диагноз кую бүлегенең ультратавыш диагностикасы табибы **Савельева** Наталия Александровна Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Новикова** Клавдия Николаевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Әлмәт политехника техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Баһманов** Илдар Рәис улына, «Җәмәле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел укытучысы **Вәлиева** Гөлфия Әнәс кызына, Казан шәһәре Яңа Савин районының «179 номерлы гимназия – мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең география укытучысы **Вилкова** Людмила Петровнага, «Казан шәһәре халыкара мәктәбе» автоном коммерциячел булмаган гомуми белем бирү оешмасының математика укытучысы **Гаврилова** Наталья Николаевнага, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Октябрь урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Гыйззәтуллина** Марина Владимировнага, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркваш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Гыйниятова** Наталья Аркадьевнага, «Е.Н. Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директорының уку-укыту эше буенча урынбасары **Зәкиуллина** Елена Аликовнага, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Кызыл Тау «Радуга» балалар бакчасы» муниципаль бюджет катнаш төрдәге мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе **Клинова** Вера Владимировнага, Казан шәһәре Идел буе районының «Татар телендә белем бирелә торган 18 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Садыйков** Равил Хәсәнша улына, Казан шәһәре Яңа Савин районының «103 номерлы урта гомуми белем бирү рус-татар мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Хәбибуллин** Ринат Нәкыйп улына, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «147 номерлы урта гомуми белем бирү рус-татар мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы **Шиһапова** Гөлгенә Габделбәр кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 4 март, 2022 ел, №168/1430 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров районы территориясендә оештырылган участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров районы территориясендә оештырылган участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр итә.

Тәкъдимнәр һәм кирәкле документлар кабул итү Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров район территориаль сайлау комиссиясе тарафыннан 2022 елның 5 мартыннан 22 мартка кадәр хәл ителә:

– эш көннәрендә 09.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты – 12.00-13.00 сәгатькәчә)

Территориаль сайлау комиссиясе (ТИК) атамасы	Территориаль сайлау комиссиясе адресы
ТР, Казан ш., Киров районы ТИК	420095, Казан ш., Восстание ур., 82 й., 517 каб. (код 8-843) тел.: 223-29-99 өстәмә (3781)

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 29 статьясындагы 1 пунктындагы таләпләргә туры килмәүче затлар, тәгаенләп әйткәндә:

– Россия Федерациясе гражданлыгына ия булмаган затлар, шулай ук чит ил гражданлыгына ия булучы яки Россия Федерациясе гражданинының чит дәүләт территориясендә даими яшәүгә хокукын раслаган башка документка ия булучы Россия Федерациясе гражданнары;

– законлы көченә кергән суд карары нигезенә эшкә сәләтсез, эшкә сәләте чикләнгән дип танылган Россия Федерациясе гражданнары;

– 18 яшькә җитмәгән Россия Федерациясе гражданнары;

– дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары, җирле үзидарә органнары депутатлары;

– сайланылулы вазифаи затлар, шулай ук җирле хакимиятләр башлыклары;

– судьялар (отставкадагы судьялардан тыш), прокурорлар;

– суд карары нигезендә комиссияләр составыннан чыгарылган затлар, шулай ук комиссияне таркату нәтиҗәсендә хәлиткеч тавыш хокукы белән комиссияләр әгъзалары вәкаләтләрен җуйган затлар (комиссия тарафыннан закон бозулар өчен суд тарафыннан үзләренә карата гаепләрнең юклыгы билгеләнгән затлардан тыш) – тиешле суд карары законлы көченә кергәннән соң биш ел эчендә;

– үзләреннән хөкем җәзасы алынмаган затлар, шулай ук сайлаулар һәм референдумнар турында законны бозган өчен суд тәртибендә административ җәзага тартылган затлар – административ җәза билгеләү турында суд карары законлы көченә кергәннән соң бер ел эчендә, кандидатуралары кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертү өчен кирәкле документлары булмаган кандидатуралар участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кертү өчен кирәкле документлар исемлеге

Сәяси партияләр, аларның төбәк бүлекләре, башка структур подразделениеләре өчен:

1. Сәяси партиянең яки төбәк бүлегенең, сәяси партиянең башка структур подразделениесенең участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында сәяси партия уставы таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.

2. Кандидатуралар турында тәкъдим сәяси партиянең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесе тарафыннан кертелеп, сәяси партия уставында мондый тәкъдим кертү мөмкинлеге күздә тотылмаганда – сәяси партиянең төбәк бүлегенә, башка структур подразделениесенә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертүгә вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле сәяси партия органының әлеге вәкаләтләрне бирү турында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.

Башка иҗтимагый берләшмәләр өчен:

1. Иҗтимагый берләшмәнең гамәлдәге уставының нотариуста расланган яки иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле органы раслаган күчермәсе.

2. Иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары яисә төбәк бүлегенең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының яисә иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә иҗтимагый берләшмә исеменнән мондый карар кабул итүгә хокук бирелгән иҗтимагый берләшмәнең башка структур подразделениесе карары.

3. Кандидатуралар турында тәкъдимне иҗтимагый берләшмәнең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесе кертеп, иҗтимагый берләшмә уставында 2 пунктта күрсәтелгән мәсьәлә җайга салынмаганда – иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү буенча вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле иҗтимагый берләшмә органының мондый вәкаләтләрне бирү турында карары һәм әлеге вәкаләтләр бирелгән органның участок сайлау комиссияләре составлары резервына тәкъдимнәр кертү турында карары.

Участок комиссияләре составлары резервына кандидатуралар кертү хокукының башка субъектлары өчен

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары, яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыны буенча сайлаучылар җыелышының беркетмәсе. Сайлаучылар җыелышы беркетмәсенең формасы Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, №152/1137-6 карары (Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 1 ноябрь, 2017 ел, №108/903-7 карары редакциясендә) белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә №3 кушымтада китерелгән.

Моннан тыш кандидатуралар кертү хокукының барлык субъектлары тарафыннан түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш:

1. Россия Федерациясе гражданинының хәлиткеч тавыш хокукы белән участок сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләнүенә, участок комиссияләре составлары резервына кертүгә язмача ризалыгы (Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, №152/1137-6 карары (Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 1 ноябрь, 2017 ел, №108/903-7 карары редакциясендә) белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә №1 кушымта).

2. Россия Федерациясе гражданины паспорты яки кандидатурасы участок комиссияләре составлары резервына кертү өчен тәкъдим ителгән затның гражданлыгы һәм яшәү урыны турында мәгълүматлардан торган Россия Федерациясе гражданины паспортын алыштыручы документы күчермәсе.

Искәрмә. Документлар үрнәкләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына «Сайлау комиссияләре» бүлегендәге «Участок комиссияләре составлары резервы» «2022 елда участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә кертү» бүлекчәсенә урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

«Айкала суларыгыз...»

Чын җырчылар гына нинди җырга тотынса, шуны җиренә җиткереп башкара. Бу андый түгел иде. Ул бары тик бер җыр гына белә, аны да чын җырчылар кебек манчый алмый, шулай да «Минский» матаенда җил ертып барганда үз тавышы үзенә искиткеч дәрәҗәдә матур булып ишетелә, шул матурлыктан илһамланып, ул күкрәк тирәненнән килгән бер тавыш белән сузып җибәрә иде:

Айкала суларыгыз, чайкала суларыгыз,
Кайсы йолдызлар астында
Йөрегән юлларыгыз...

Матайның арткы урынында утырып, бар булмышы белән үзенә сеңеп барган сөйгән яры да җырлыйдыр сыман тоела. Юк инде... Сөйгән яры җырламый аның... Ул бары тик егетенең моңлануын гына тыңлый. Егетенең дәртле дә, моңлы да тавышы аңа канат куя. Йөрәге күкрәк читлегеннән атылып чыгардай булып ярсып тибә. Егет аның йөрәк тибешен тоеп бара. Калак сөякләренә сарылган назлы күкрәкләр тибрәлешен дә, сөйгән кызының йөрәк тибешен дә тоя. Кайвакыт кыз йөрәге үз күкрәгендә тибәдер кебек тоела. Дөп-дөп, дөп-дөп... Һәм ул үзен куш йөрәкле кеше кебек хис итә. Хис итә дию генә дөрес түгелдер. Ул чынлап та куш йөрәкле бугай. Бөтен җаны-тәне мәхәббәт белән тулган ир-егетләр чынлап та куш йөрәкле буладыр. Бу бернинди арттыру да түгел. Синең күкрәгеңдә ике йөрәк тибә – үзеңнеке һәм сөйгәнеңнеке.

Һәм ул беләзекләре өзелеп китәрлек итеп матаеның газын ача да двигательнең дәртле ажгыруына кушылып яраткан җырын сузып җибәрә:

Айкала суларыгыз, чайкала суларыгыз...

Тирә-якта бернинди су-фәлән булмаса да, ул сулар айкалышын, дулкыннар чайкалышын тоеп бара. Һава чайкала. Дөнья айкала. Аларның көчле мәхәббәте, барысын да айкап-чайкап, үзләренә юл ачып бара. Алар тормышның бөтен авырлык-сынауларын җиңел генә ерып, үз бәхетләренә каршы җилдерәләр. Алар гомерне ертып баралар. Алар шундый көчле һәм бәхетле, юлларына берни дә аркылы төшмәс, төшә алмас, төшсә дә, бик тиз җиңелер сыман тоела.

Кинәт әллә кайдан бер болыт килеп чыга да бөтен дөньяны чылатып уза. Бу аларның бәхетен киметми, бу бары тик хисләрне һәм күңелдә калкынган сурәтләрне генә баета. Битләргә кунып чәрдәкләнеп очкан яңгыр тамчылары аларның гайрәтен, берничә дә бирешмәслек көчен куәтләгән кебек кенә була. Яңгыр аларга каршы ява. Һәм мең төсмерләргә бүлгәләнеп чәрдәкләнә. Һәм алар бөтен каршылыкны ертып алга бара. Кинәт нәрсәдер була. Әллә юл артык юешләнә, әллә егетнең хисләрдән ташкан күңеле тибрәнеп китә... Матай бар дөньяны ертып барган уңайга аркылыга баса. Кыз чыелдау авазы чыгарып егетенә ныграк сыена. Егет шул ләззәттән исереп, газны ача төшә һәм бөтенләй башка үлчәмгә күчеп җырын яңадан башлый:

Айкала суларыгыз, чайкала суларыгыз...

Сулар гына айкалмый инде. Бөтен дөнья айкала. Юлга аркылы шуган матай тәгәрмәченә эләккән юеш балчык өсләренә чәчри. Бөтен киемнәрен, чәч-битләрен, өс-башларын пычратырга тырыша. Иреннәрдә аның тәме пәйда була, күзләргә чәчрәгәне яшь чыгара... Болар инде бәхетләренең чиген бәреп чыгып һәлакәткә баргандай тоелалар. Тик күңелләрендә андый бер тойгы юк. Алар көләләр. Бөтен дөньяны аларның бәхет авазы телә. Шушы авазлар гына да бөтен дөньяны бәхетле итәргә җитәр шикелле тоела. Бер мәлне матай кайдадыр читкә оча. Егет белән кыз тәкмәчли-тәкмәчли әйләнәләр дә тынып калалар. Бераздан торып утыралар. Аякларына басалар. Аксаклый-аксаклый матайларына табан атлыйлар. Һәм бер-берсенә караш ташлыйлар да бар дөньяны яңгыратып көләргә тотыналар. Тәгәрмәчләре ярсып әйләнеп яткан матай янына килеп җиткәч туктап калалар. Һәм егет тау түбәнендә җәйрәп яткан авылга караш ташлый да җырын дәвам итә:

Айкала суларыгыз, чайкала суларыгыз...

Алар икесе дә кара ләмгә баткан... Бер-берсенә наз сибүче күзләре һәм тешләре генә балкый. Болытлар читеннән ымсындырып җиргә баккан кояш шикелле. Боларның икесе бер елмаю сыман. Бу елмаюны һәм шушы яктылыктан таралган моңны капларлык кара болыт, өзәрлек бер көч юк шикелле иде.

Сугыш өзде.

Сугыш ул мәңге өзелмәстәй тоелган нәрсәләрне дә өзә.

Егет Ватаны кушкан өчен чит җирләргә барып хәрби бурычын үтәп кайтты. Кызы көтеп алды. Ул аның нәкъ менә шушы вакыттагыча самимилеген, яктылыгын, моңлануын көтте. Сүз белән әйтмәсә дә, аның матай газын ачып җибәргәндәй яшәү тизлеген арттырып, дәртле дә, моңлы да җыр сузуын көтте. Хәтта бөтен дөньяларын кара кайгы басып алганда да күзләре һәм тешләре генә ялтырап торадыр, һәм хәзер аның сөйгәне күкрәк тирәненнән алып җыр сузып җибәрер шикелле тоелды:

Айкала суларыгыз, чайкала суларыгыз...

Тик аның сөйгәне бүтән җырламады. Аның күз карашлары да, елмаюлары да бүтән иде. Гомере буе көтеп яшәсә дә, аның җырын терелтергә тырышса да – берни дә килеп чыкмады. Ә соңыннан ул аңлады инде... Сөйгән ярының җырын сугыш үтергән иде. Җыр өзелгән иде. Сөйгәне исән кайтса да, җыры үлгән иде.

Әле менә, утыз ел бергә яшәгәннән соң, үзе дә чайкала-чайкала урам буйлап җыр сузып кайтып килә. Әллә шул чакларын сагына ул, әллә җырсыз үткән гомерен җәлли, әллә ятып калган дусларын искә ала, әллә... Кем белә инде... Карчыгы бөтен ачу-үпкәләрен онытып, аңа каршы атлый. Керфек очларында күз яшьләре, иреннәрендә елмаю тибрәлә. Ә иренең тавышы төнге авыл тынлыгын телгәли:

Айкала суларыгыз, чайкала суларыгыз...

«ВТ» архивыннан

Газетаның киләсе саны 11 мартта чыга

БЕР НАЗЛЫ СҮЗ ҖИТӘ...

mger.ru

8 Март бәйрәмен һәркем үзенчә аңлый. Кемдер бу көнне зур бүләк өмет итә, кайберәүләргә – бер чәчәк, икенчеләргә назлы сүз дә җитә. «ВТ» гүзәл затлардан иң истә калган яз бәйрәме хакында сорашты.

Наилә ГАРИФУЛЛИНА, 20 нче гимназиянең директор урынбасары:
– Кечкенәдән безнең өчен Әни бәйрәме иде ул. Нигәдер ул чакта безгә бүләк бирүче булмады. Хәзер исә кызларымны бәйрәм икәнен белеп үсәргә өйрәтәм. Өчесенә дә төрле бүләкләр алабыз. Әтиләре беребезне дә чәчәксез калдырмый. Ел да лаләләр бүләк итә. Бәйрәм тоташ ялларга туры килсә, авылга кайтырга дип ашкынып торабыз. Анда эш күп. Түбәдән кар төшерәсе бар. Аннары якыннар белән җыелып чәй эчү дә бәйрәмгә әйләнә.

ИРКӘ, Татарстанның атказанган артисты:
– Без бәләкәй чакта бу бәйрәмне әниләрнеке дип белә идек. Үземә ниндидер бүләк биргәннәрен хәтерләмим. Хәзер кызларым үз куллары белән ясап биргән эшләр – иң кадерлесе. Ирем дә – талантлы кеше. Ул картиналар ясый. Мине шаккатырырга ярата. Бер елны ваннага кереп китте дә өч сәгать чыкмады. Нишли икән соң бу, дим. Баксаң, миңа дип 8 Мартка картина ясаган. Гаиләбез бәйрәмнәргә зур чыгымнар түгү яклы түгел. Авылда чакта да әниемә әтиемнең әллә нинди бүләкләр биргәнен хәтерләмим. Авыл ирләре башкача бит инде алар. Заманасы да икенчерәк иде. Әмма моннан биш ел элек әтинең әнине шатландырганын хәтерлим. Бу бөтенебез өчен көтелмәгәнчә булды. Әти әниемә күлмәк, яулык, чәчәк алып кайткан иде. Менә монысы, чынлап та, истә калырлык булды.

Нурсимә ГАЛИМОВА, почта хезмәткәре:
– Ирем ел саен 8 Мартка кыйммәтле бүләкләр бирергә тырыша. Өйләнешкәч тә, чәшке тун күтәреп кайтканына аптыраган идем. Кайдан үлчәмемне белгән, ничек итеп төсен сайлаган – шаккаттым. Баштарак акчасын әрәм иткән дип борчылган да идем әле. Тик каенанам, рәхмәтеңне әйтеп, бүләк кабул итәргә өйрән, безне котлый белмәделәр, дигән киңәшен бирде. Улын хатын-кызны олыларга, кадерләргә өйрәткәне өчен рәхмәтем чиксез аңа. Ирем юктан да күңелне күрә, гадәти көнне дә бәйрәмгә әйләндерә. Мин исә, туннар алып бирмәсәм дә, икебезгә санаторийга юллама алам, кайчак матурлык салоннарына, массажга бергә барабыз.

Ләйсән САДЫЙКОВА, өч малай әнисе:
– Яз җитүгә, күңел үзеннән-үзе бәйрәм тели башлый. Бәйрәмгә бүләкне сорап алмыйм. Ни бирсәләр, шуңа ризамын. Әмма моннан 4 ел элек иремнең бәйрәмгә Төркиягә барырга юллама бүләк итүе әле дә исемдә. Ирем Дамир кайтты да: «Быел ял бүләк итәм», – диде. Минем өчен иң кирәкле әйбер шул инде. Көтелмәгән бүләк күңелемне күтәрә. Чәчәкләр яратмыйм, ә менә улларымның үз кулы белән ясалган язгы бүләкләрен кадерләп саклыйм. Аеруча балалар бакчасында ясаганнары кадерле. 8 Март бәйрәмендә ике яктан да әниләребезне һәм сыйныф җитәкчемне сөендерергә яратам.

Илсөяр ДӘҮЛӘТШИНА, хуҗабикә:
– Бу көнне мин икеләтә бүләк алам. Якыннарым туган көнем белән дә котлыйлар. Бүләккә саранланмыйлар. Берьюлы икене бирәләр. Әмма минем яраткан бүләгем – чәчәк белән торт. Ирем Шамил исә бу көнне иртән йокыдан тора да «тәмле» теле белән матур сүзләр әйтеп, күңелне эретә. Сүзен әйтеп бетергәч, бу айдагы хезмәт хакым синеке, дип тә өстәп куя. Ел саен шушы хәл. Мине 59 ел элек дөньяга китергән әниемне дә онытмыйбыз. Шөкер, быел 80 яшен тутырды. Кайчандыр мин аңа бүләк булсам, хәзер аның булуы – минем өчен зур бәхет.

Миләүшә ӘБСӘЛӘМОВА, Франциядә яшәүче милләттәшебез:
– Франциядә хатын-кызлар бәйрәме юк, 8 март гадәти эш көне санала. Моңа ияләндем инде. Әмма кайбер елларда Россиядән килгән дусларым белән җыелышып бәйрәм итәбез. Иремнең бу датага исе китми, чәчәк алырга да оныта. Моның өчен үпкәләшмибез инде. Аның каравы монда 14 февраль – Гашыйклар көне, Әниләр бәйрәме зурлап үткәрелә. Бу көнне чәчәкләргә дә, бүләкләргә дә күмәләр.

Ләйсән ШӘРИПОВА, банк хезмәткәре:
– Мин бик тә концерт-театрлар яратам. Иремә алдан ук әйтеп куйдым – акчаны юк-барга туздырмаска кирәк. Бәйрәм көннәрендә уздырылган чараларга йөрибез. Гаиләбез белән айга бер тапкыр ресторанга бару гадәтен керттек. Яз бәйрәменең чәчәксез узганы юк. Үзем дә бүләк итәргә яраттам, биргәннәренә дә рәхмәтлемен.

Әлфия ГАЛИӘХМӘТОВА, блогер:
– Элек бәйрәмгә кульяулыклар чигеп әзерләнә идек. Кечкенә якта концерт куйганыбыз әле дә онытылмый. Ә менә иң истә калганы – Назыйм абыебызның моннан өч ел элек сиздермичә генә бриллиант кашлы йөзек алып кайтканы. Иң беренче сүзем, кыйбат булган, дим. Әмма хәзер инде яратып киеп йөрим. Ә балаларым кыйммәтле телефон алып биреп сөендергән иде. Үзем дә кызларыма бүләк әзерләп куйдым. Венерам Түбән Камада яшәгәч, әкрен генә, сиңа нинди ислемай ошый, дип сораган булдым да шуңа заказ бирдем. Илүзәм Казанда торгач, мин аны бәйрәм белән котлап картасына акча салам. Үзенә кирәк әйберне ала.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

МИН – СӘЕР ЗӨЛФӘТ!

Аңлап булмый аны: ул – беркатлы сабый кебек тә, шул ук вакытта чишелмәс табышмак та. Тормышта үз кагыйдәләре дә бар. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, элеккеге хезмәттәшебез Зөлфәт абый Хәйруллин март аенда 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Хәзер аның гаиләм, оныкларым, бакчам, иҗатым дип яшәп яткан рәхәт мәле.

Газетабызда 30 елга якын җаваплы сәркатип урынбасары булып эшләде ул. Бертөрлелек туйдырганда, арып киткәндә, күңелгә нәкъ менә аның кебекләр кирәк. Йә ул баянын алып, сыздырып җырлап җибәрә, йә үзең сизмәгәндә, кәгазь битенә ике-өч минутта кыяфәтеңне төшереп куя, йә артистлана, кылана ук башлый.

– Сәерлек бик көчле миндә. Иҗат кешесе шундый булырга тиеш. Тик торганда үз-үзем белән сөйләшә, кычкыра, үкерә башлыйм. Бу юләрлекләремә «клип» дигән исем куштым. Озак шалтыратмасам, танышларым «Ватсап»тан клип җибәрүемне сорый. Үкерүемне тыңлагач, аларга да рәхәт булып китә. Кайберәүләр миннән ераграк торырга тырыша, телефоннарын да алмыйлар. «Хатының ничек түзә?» – диючеләр дә юк түгел. Мин үз кыланмышларымны яшермим. Шул ук вакытта моны башкаларга зыян сала дип тә уйламыйм, – ди ул.

Тормышта – үз принциплары. Аларны кешеләргә сиздермәскә, кирәкмәгән җиргә кысылмаска тырыша. Бер төрле сөйләп, икенче төрле эшләүчеләрне җене сөйми. Булганына риза булып яшәвен дәвам итә. Тырышып кына да бик алга китеп булмый, уңыш елмаю да кирәк, ди. Аның өчен ак һәм кара дигән нәрсә бар. Карага бөтенләй кагыласы түгел! Кызлары Ләйсән белән Рузиләне яхшы белән яманны аерырга өйрәтеп үстергән. Хәзер оныкларын карарга булыша. Җырлата, биетә, әкиятләр сөйли, кулларына пумала тоттырып, рәсемен дә ясата дәү әти.

Үз куллары белән бакчасында өй, мунча салган, бакча ясаган. Үзе калайчы, балта остасы, электрчы, буяучы, рәссам, бакчачы. Хатын-кыз эше дип аптырап тормый. Керләр юарга, тегәргә ярата. Тик ашарга пешерә белми. Хәер, 40 ел хатын белән яшәүче иргә монысы мөһим дә түгелдер. Тәмле ризыклар белән сыйлап торучы, кәефсез чакта күңелен күтәрүче хатыны Рәзинәсе бар бит!

Зөлфәт абый дигәндә, шаржлар турында әйтми калып буламы соң? Рәсемнәренең матбугатта басыла башлавына – 33 ел. «Башым идеяләр белән тулган. Ясаласы иң шәп шаржлар алда әле», – ди Зөлфәт абый.

Аның фикеренчә, шарж жанры үзгәрергә мөмкин. Чөнки Зөлфәт Хәйруллин 4–5 сызык белән кешегә шарж ясап, аның бөтен холкын, кем икәнен күрсәтергә уйлый. «Кайбер вакытларда ул килеп тә чыга. Бу сәнгатьтә – үз юлым. Барысы да берничә секундта, минутта эшләнергә тиеш. Шуңа мине Камил Кәримов «рәссам-моменталист» дип атады», – ди шаржлар остасы.

Татар рәссамнарыннан беренчеләрдән булып, сәхнәдән үзе теләгән теләсә кемгә шарж-рәсемнәр ясаучы да ул. Туйларда, юбилейларда 40–50шәр кешегә рәсемнәрен ясап биргәне бар. Мәҗлесләргә аны махсус шаржчы итеп чакыралар. Аның өчен иң зур бүләк – шаржлары басылу. Язучы Зәки Зәйнуллин: «Зөлфәт, син шаржлар гына ясарга тиеш, язарга да, гармун уйнарга да тиеш түгел!» – дигән. Дөрес, көлкене аңлап бетермәүчеләр дә очрый. Шагыйрь Нариман Камалов шарж ясагач үпкәләп, ертып ук аткан. Ә менә элеккеге прокурор Кафил Әмиров бик риза калган, заманасында хәтта шаржлар китабын бастырырга да ярдәм иткән.

– Күпме яшим, шуның кадәр иҗат итәрмен дип уйлыйм. Әле картиналар ясарга, баянда яңа җырлар өйрәнергә исәп. Күңел һаман 18дә. Иҗат кешесе картаймый. Тормышым үкенерлек түгел. Китабым чыкты, мәдәният институтында шаржлар галереясы ачылды. Казанда, туган ягымда иҗат кичәләрем гөрләп үтте. Яз җитүгә, бакчаны тәртипләргә китәчәкмен. Җирдә казынып яшәү көч бирә. Илһамланырга, хыялланырга да җитә ул, – ди Зөлфәт Хәйруллин.

6 мартта туган ягы Балтач районының Чапшар авылында Зөлфәт Хәйруллинның иҗат кичәсе үтәчәк. Иҗатын яратучыларның барысын да әлеге кичәгә чакыра. Зөлфәт абыйны юбилее белән котлап, сәламәтлек, күңел тынычлыгы, хатыны Рәзинә белән тигезлектә яшәвен телибез.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7101 данә
Гомуми тираж – 17132 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 232

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+